**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__30__» ____01____ 2026 ел.** **№ _19_**

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы «2026 елда түләүләр, акчалата ярдәм һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2025 елның 28 маендагы 340-45 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итүгә бәйле рәвештә, Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы килешүне исәпкә алып, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының авыл җирлекләрендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2026 елның 01 февраленнән 1 нче һәм 2 нче кушымталарга туры китереп 9 678, 63 (тугыз мең алты йөз җитмеш сигез сум алтмыш өч тиен) күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары Р.Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
«___»__________2026 №_________

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
бәясенең чик күләме

| **№** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 200,00 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 2 000,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 478,63 |
| **4** | **Барлыгы** | **9 678,63** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
«___»__________2026 №_________

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыда
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
бәясенең чик күләме

| **№** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 1 600,00 |
| 2 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 600,00 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 2 000,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 478,63 |
| **5** | **Барлыгы** | **9 678,63** |